Казан
(Идел буе)
федераль
университеты
газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 1
(14)

19 гыйнвар
2012 ел

## • Ректорат яңалыклары

16 гыйнвар көнне чираттагы ректорат узды. Беренче булып икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллин 2011 елда КФУның Үсеш программасын тормышка ашыру турында нәтиҗә ясады.

Халыкара эшчәнлек турында тышкы элемтәләр буенча проректор Л.Латыйпов сөйләде. Әлеге эшчәнлек төп өч юнәлеш буенча тормышка ашырыла: мәгариф, фән һәм халыкара эшчәнлек менеджменты. «Моның өчен чит ил партнерлары белән уртак программалар булдырырга, дөньяның алдынгы галимнәрен лекцияләр укырга чакырырга, чит ил гражданнарын безгә укырга кабул итәргә кирәк», – диде ул.

Февраль аеннан яңа сайт эшли башлаячак. Җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлеге җитәкчесе Л.Мөхтәрова яңа сайт белән таныштырды. Аңа сизелерлек үзгәрешләр кертелгән. Университет белән бәйле һәр мәгълүматны табарга мөмкин булачак. Бүгенге сайттан аермалы буларак, бүлек турында мәгълүмат мең билгедән артмый. Күбрәк фотосурәтләр бирелә, аерым википедия ясалачак. Анда бүлек, галимнәр турында фикерләр күрергә мөмкин булачак. Китапханә, музей, тулай торак турында тулы мәгълүматлар бар. Университет картасы да булачак. Шулай ук һәркем яңалык, белдерү элә алачак, ләкин аларны белгечләр тикшерәчәк. Бу уңайдан фикерләр, теләк-тәкъдимнәр күп булды. «Аларның һәркайсы искә алыначак. Филология һәм сәнгать институты сайтының эшләнеше миңа бик ошый», – диде ректор И.Гафуров.

2012 елга кабул итү буенча Физика институтының директор урынбасары Д.Таюрский чыгыш ясады. «Мәктәпләрдә физиканың нәрсә икәнен бөтенләй оныттылар. Бу фәннән БДИ бирүчеләр бик аз, чөнки директорлар алдан ук куркытып тора, мәктәпнең дәрәҗәсен төшерәсе килми. Быелгы I курсларга мәктәпне тәмамлаганда тапшырган БДИ бирдереп карадык. Уртача балл 39 га ким. 3 ай эчендә укучы бар белгәнен оныта дигән сүз. Шуңа күрә сессиягә кертелми калган студентлар да күп», – диде ул. Абитуриентларны җәлеп итү өчен, яңа юнәлешләр ачылачак. Җитәкче сүзләренчә, аеруча ата-аналар, укытучылар белән эшләргә кирәк, чөнки балага төп басымны алар ясый. 78% студент алар фикере белән бирегә укырга кергән, бары тик 5% кына белгечлек турында реклама буенча ишеткән.

Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты директоры В.Чугунов, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты директоры Р.Латыйпов шулай ук кабул итү турында мәгълүмат җиткерде, абитуриентларны җәлеп итү өчен, нинди чаралар куллануы турында сөйләде. Бу уңайдан ректор үз фикерләрен әйтте: «Укучы алдына сорауны дөрес куя белергә кирәк: син кем булырга телисең һәм кем була аласың? Кемдер булу өчен, син нәрсә белергә тиеш? Социаль сайтларда укучылар арасында сорау алу үткәрергә, аларның фикерен, теләкләрен белергә кирәк. Кызыксыну, ихтыяҗ уянсын өчен, психологик якка да басым ясау, алар телендә сөйләшергә өйрәнү мөһим. Мәктәп директорлары, укытучылар белән эшләү мәҗбүри фактор. Аларны шулай ук кызыксындырырга, хезмәттәшлек итәргә чакырырга кирәк», – диде. Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбе директоры А.Хасьянов та планнары белән уртаклашты.

Төрлеләр өлешендә фәнни эшчәнлек буенча проректор Д.Нургалиев хезмәт хакына КФУ ректоры исемендәге өстәмә түләү алачак кандидатлар белән таныштырды. Ректор приказы белән фән, спорт, мәдәният өлкәсендә зур уңышларга ирешкән, актив иҗтимагый эшчәнлек алып барган, халыкара бәйге һәм олимпиадаларда лауреат булган 20-30 яшь галим, хезмәткәрнең хезмәт хакына 10 мең сум тирәсе акча өстәләчәк. Ул бер елга каралган.

КФУ биналарының элмә такталары турында әйдәп баручы архитектор Н.Хәмидуллина чыгыш ясады. Ул элмә такталарны берничә вариантта тәкъдим итте. Берничә төрле фикер яңгырады, алар һәркайсы исәпкә алыначак.

*Динара ӘХМӘТОВА,*
*хәбәрче*



Алия Галимуллина фотосы

# Тәүге чирканчык

**Алсу НУРГАТИНА,**
журналистика һәм социология факультеты студенты

Үзенең очсыз-кырыйсыз шаянлыклары, дөресне бер кызыклы вакыйгага әверелдерә белгән дуслары һәм синең укуың, билгеләрең өчен янып йөргән укытучылары белән мәктәп еллары үтеп китте... Хәзер киң адымнар белән студент дөньясына аяк бастык.

«Мәктәп еллары үзенә бер кызык, монда әле балачак озата бара, ә студент еллары – үсмер чактан зур тормышка аяк басу ул. Монысы тагын да кызыграк», – дия иде укып бетергән апа-абыйлар әле без башлангыч сыйныфта «койрыклар» белән көрәшкәндә. Шул вакытларга без дә кызыгып карый идек...

Студент кайчан чын студент була?! Әлбәттә, тәүге сессияне тапшыргач. Айлар буе әвеш-тәвеш килеп укып йөргәндәй иткән лекцияләрне ул зур бер тәртипкә сала. Өч ай буена «аңлашылмаган» темаларның бер төн эчендә серенә төшенәсең! Алай гына да түгел, сессия вакытында уйларда гел уку. Шәһәр гүзәллекләре дә, кичке Казан тормышы да, берсеннән-берсе татлы тәгамнәр сатылган киосклар да бер читтә кала. Хәтта йокыны да сагынып искә аласың! Иң мөһиме, башкалардан калыйшмыйча, сессияне ябып куярга.

Минем өчен сессия әкияти Каф тавына тиң иде ул. Беренчедән, Яңа ел бәйрәмнәренә кадәр зачетлар бирәсе, Яңа елдан соң колач җәеп имтиханнар көтә! Зачетлар тапшыру үзе бер кызык! Бар сорауларга да җавап эзләгәндә: «Эх, кайсы сорау кабасын алдан ук беләсе иде», – дип уйлап куясың. Ләкин юк, барысын да әзерләп барудан башка берни дә калмый!

Бәйрәм тәэсирләреннән арынгач, авылдан Казанга килгәндә, имтиханнар каршы алды. Аларга әзерлек түбәндәгечә барды: имтиханнар арасы – өч көн! Шушы өч көндә булган билетларны карап, өйрәнеп чыгарга кирәк. Тулай торакта яшәсәң, төркемдәшләр белән бергә җыелып әзерләнсәң дә була. Шәхсән мин шулай иттем. Ә Казаннан ерак булмаган районнар үзләренә кайтып китте. Зачетларны Яңа ел, дип тапшырсаң, имтиханнарда каникул, дип ашкынасың. Мәктәптәге төсле каникуллар күп әләкми шул. Көз-язларны сызып аталар да кыш һәм җәй каникуллары гына кала. Шуңа да кышын авылга кайтып, әти-әнигә ярдәм итеп, авыл карларында да ауныйсы бар бит әле! Шундыйрак уйлар белән билетның икенче соравына күчәсең.

**Ахыры 2нче биттә.**

## • Сезне бездә көтәләр

# Галимнәр сәфәр чыкты

**Рөстәм ФӘРХУЛЛИН,**
Экология һәм география институты ассистенты

Элек югары уку йортларында «урак өсте» июнь-июль айларына туры килсә, бүген абитуриентларны кабул итүгә бәйле эшчәнлек ел дәвамында бара. Факультет-институтларның галим-мөгаллимнәре үзләрендә генә ачык ишекләр көне уздырып калмый, төрле районнарга да еш чыга.

Шул рәвешле, безнең Экология һәм география институтының И.Т.Гайсин, И.Ә.Уразмәтов, Г.Р.Сафина, Г.С.Самигуллина, Р.А.Уленгов, М.М.Зәйниев, Р.Ш.Фәрхуллин кебек галим-мөгаллимнәреннән торган делегация 13 гыйнвар көнне Балык Бистәсендә булып кайтты.




**Ахыры 2нче биттә.**

**• Ике авыз сүз**

17 гыйнвар көнне КФУ ректоры Илшат Гафуров «Каспиан Энерджи Ресерч» компаниясе генераль директоры Арман Джамикешов белән очрашты. Хезмәттәшлек турында сөйләшүләр ябык ишекләр артында узды. Казакъстан компаниясе геология, кара алтын һәм газ өлкәсе буенча куллануychыларга хезмәт күрсәтә. «Максатыбыз: кара алтын эшкәртү буенча уртак предприятие ачу. Безнең хезмәткәрләргә КФУда белем алу бик файдалы һәм дәрәҗәле булачак», – диде Арман Джамикешов.

• • • •

Шул ук көнне төрки телләрне чагыштырма-тарихи планда өйрәнүгә нигез салган танылган галим В.В.Радловның (1837-1918) тууына 175 ел тулу уңаеннан, Филология һәм сәнгать институтында фәнни конференция узды. Конференциядә татар филологиясе бүлегенең танылган галимнәре, укытучылар һәм аспирантлар катнашты. Эш барышында галимнең тормышы һәм фәнни эшчәнлеге, төрки телләр, татар әдәби теле тарихы, хәзерге төрки телләр һәм диалектлар һәм башка темаларга чыгышлар тыңланды.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

# Тәүге чирканчык

**Башы 1нче биттә.**

Зачетка да, имтиханга да әзерләнгәндә, алыштыргысызы – өлкән курс студентлары. Кайсы укытучы нәрсә ярата: сорауларны ничек бирә, озак сөйләргә мәҗбүр итәме һ.б. мәсьәләләр белән алар янына йөгерәсең. Өлгерсәң, алар әзерләнгән сорауларга җавапларны да эләктереп була.

Беренче сессияне тапшыргач, чыннан да, бозлы суга чумып, тәүге чирканчык аласың. Кат-кат әзерләнеп, белә торган соравыңа җавап биреп, «биш»ле алып чыкканда, адреналин, аяк табаныннан башлап, баш түбәсенә кадәр күтәрелә, шатлыгыңнан, ишектән чыккач, беренче очраган кешеңне кочаклап та аласың!

Шуны да әйтәсе килә: сессия ул үзе бер тормыш, үзе бер дөнья икән...

# Галимнәр сәфәр чыкты

**Башы 1нче биттә.**

1 нче гимназия базасында район укучылары, аларның әти-әниләре һәм укытучылар өчен Экология һәм география институты көне узды. Биредә 10-11 сыйныфларда белем алучы 175 укучы, 63 мәктәп директоры, география һәм биология укытучысы җыелган иде.

Әүвәл Экология һәм география институты турындагы презентация тәкъдим ителде. Соңрак исә укучыларга «География һәм биологиядән БДИга әзерләү системасы» дип аталган ачык дәрестә катнашу мөмкинлеге тудырылды. Әлеге дәрес нәтиҗәсендә алар Казан федераль университетына укырга керү шартлары, география һәм биология фәннәреннән БДИ тапшыруга бәйле таләпләр белән таныштылар. Шулай ук укучылар өчен «Нинди һөнәр сайларга» темасына анкеталаштыру да уздырылды.

Мәктәп директорлары һәм укытучылары исә «Заманча белем бирү шартларында гомуми һәм һөнәри уку йортларының интеграциясе» дип аталган «түгәрәк өстәл»дә, «Табигый-география фәннәрен укытуда мәгълүмати технологияләр» мастер-классында катнашты.

Очрашуны оештыруда ярдәм күрсәткән Балык Бистәсе районы мәгариф бүлеге җитәкчесе И.М.Садыйковка рәхмәтебезне белдерәбез.

P.S. 18 гыйнвар көнне КФУның Алабуга филиалы галим-мөгаллимнәре шундый ук сәфәргә Менделеевск районына чыкты. Ә Ачык ишекләр көне Алабуга филиалында 29 гыйнвар көнне узачак.

**• Бездә кунак бар**

# КФУга өметләр зур

**Рәдифә ШӘФЫЙКОВА,**
ksu.ru сайты хәбәрчесе

16 гыйнвар көнне Казан федераль университетына Татарстан Республикасының Баш федераль инспекторы Рөстәм Идрисов килде.

Визит Университет тарихы музее белән танышудан башланып китте. Ректор Илшат Гафуров экспозицияләр, Актлар залы, Ленин аудиториясе белән таныштырды. Рөстәм Идрисов уку йорты эшчәнлегенә карата туган соклану хисләрен җиткерде.

Алга таба кунакны университетның бүгенге эшчәнлеге белән таныштырдылар. Ректор институт, факультет, кафедра, студент-аспирантлар, галим-укытучылар саны буенча статистик мәгълүматлар җиткерде, уку йортын үстерүгә бәйле алдынгы юнәлешләрне искәртеп үтте. Шулай ук Илшат Гафуров КФУның халыкара бәйләнешләре, мәгариф өлкәсендәге хезмәттәшлекләре турында сөйләде. Рөстәм Идрисовка Казан университетының төрле өлкәләрдә яулаган соңгы уңышлары буенча әзерләнгән күргәзмә тәкъдим ителде. Кунак ирешелгән уңышларны бик югары бәяләп: «Укытучы һәм студентларның алга омтылышлары ни дәрәҗәдә зур икәнен күреп күңел сөенә. Әлеге күргәзмә университетның үсеш юлын дөрес сайлавын күрсәтә», – диде.

Бу – Рөстәм Идрисовның Казан федераль университетына беренче килүе. «Биредә эшләүче коллективка Россиянең башка вузлары көнләшеп карар иде, миңа калса. Казан университетының нигезенә салынган тарихи миссия, бай белем Россиянең һәм Татарстанның киләчәге якты булуын күрсәтә», – диде кунак, уку йортының яхшы тәэсирләр калдыруын ассызыклап.



Алия Галимуллина фотосы

**• Тәрҗемәчеләрдә кунакта**

# Татарга тылмач кирәк...

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

КФУның Филология һәм сәнгать институтының тәрҗемәчелек һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеге иң яшь бүлекләрнең берсе. Биредә белем алу башка милләтләрнең әдәбияты, тарихы, гореф-гадәтләре белән танышу, чит телләр өйрәнү өчен зур мөмкинлекләр ача. Аның эшчәнлеге белән якыннан танышу өчен, бүлек җитәкчесе филология фәннәре докторы, профессор **Әлфия Шәүкәт кызы ЮСУПОВА** белән әңгәмә кордык.



***– Әлфия Шәүкәтовна, бүлекнең эшчәнлеге, максатлары белән якынрак таныштырып китегез әле.***

– Безнең төп максат – тәрҗемәчеләр әзерләү. Ул ике юнәлештә тормышка ашырыла: чит телләр – инглиз һәм Европа телләре, рус теленнән – татар теленә, татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү. Бүгенге көнгә кадәр тәрҗемә буенча махсус белгечләр әзерләнмәде, ул өстәмә белгечлек буларак кына барды. Бүлек ачылгач, бик күп махсус фәннәр барлыкка килде. Алар инде, әлбәттә, тәрҗемә теориясенә һәм практикага бәйле. Киләчәктә әлеге юнәлешләрне тагын да үстерербез дип уйлыйбыз. Икенчесенә берәр чит тел дә өстәп укытасы килә, чөнки бүгенге көндә ансыз булмый.

***– 2013 елда зур чара – Универсиаданы каршы алырга әзерләнәбез. Сезнең бүлектә укучы студентлар әлеге чарадан читтә калыр дип уйламыйм...***

– Әлбәттә, Универсиаданы уздыруга безнең дә ярдәмебез тиячәк. Бу уңайдан Белем бирү учреждениеләре белән эшләү департаменты директоры Миләүшә Галиуллина белән очраштык. Алга таба мондый сөйләшүләр күп булачак, безнең төп эшне билгелиячәкбез. Нигездә, безнең студентлар волонтер вазифасын башкарачак, чөнки анда чит телләрне күбрәк белгән студентлар кирәк. Безнең студентлар кимендә 4 тел белә: татар, рус, инглиз теленнән тыш, француз яисә испан, немец, итальян телләрен өйрәнәләр. Татар телен белгән студентларны да кертеп җибәрсәк, бик яхшы булыр иде. Чит ил кешесе, шушы республикага килеп, син татар телен беләсеңме, дип сораса, юк, дип әйтү оят булачак бит. Укытучылар да тик тормый, бу юнәлештә махсус ярдәмлекләр, сүзлекчәләр әзерлиләр.

***– Бүгенге көндә тәрҗемәнең торышын ничек бәялисез?***

– Бу турыда төрлечә фикер йөртергә мөмкин. Арада бик яхшы тәрҗемәчеләр, яхшы тәрҗемәләр бар. Ни өчен урамдагы тәрҗемә рекламалар чуар һәм хаталы? Төп сәбәп: бездә тәрҗемәләрне тикшереп, аңа бәя биреп, дөреслеген раслый торган оешма юк. Ул я шәһәр хакимияте, я Министрлар кабинеты карамагында булырга тиеш. Әйтик, нинди дә булса оешма татарча элмә такта эшләтә икән, барып раслатырга, белемле, профессиональ тәрҗемәчеләргә тикшертергә тиеш. Бездә күңелләре булсын дип кенә эшлиләр. Кайвакыт шундый фикер туа: бу тактаның булуыннан булмавы яхшырак түгел микән? Әгәр махсус оешма булса, тәрҗемәләр күзгә күренеп яхшырыр иде.

Бүлектә «Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы» фәнни түгәрәге эшли. Бирегә студентлар атна саен җыелалар. Түгәрәкнең максаты – студентларны тәрҗемә нигезләре белән таныштыру, сөйләм культурасын үстерү. «Студентлар тәрҗемәнең төп юнәлешләре, төрле классификацияләр, тәрҗемә тарихы белән таныша. Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итүнең теоретик һәм гамәли нигезләрен өйрәнә. Алман, инглиз телләреннән татар теленә тәрҗемә иткән эшләр дә бар», – ди фәнни җитәкчеләре филология фәннәре кандидаты, доцент Зоя Кириллова.

Түгәрәккә татар филологиясе бүлеге, тәрҗемәчелек һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеге студентлары йөри. Алдагы елларда Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара мөнәсәбәтләр институты һәм механика-математика факультеты студентлары да йөргән. «Бөтен студентлар өчен дә уңайлы вакытны табу бик авыр. Киләсе семестрда безгә бирелгән вакытны да алмакчы булалар. Студентларны мондый мөмкинлектән мәхрүм итмәсеннәр иде, чөнки бик теләп йөриләр», – ди җитәкчеләре. Хәзерге вакытта түгәрәк старостасы вазифасын Ләйлә Фәхриева башкара. Һәр утырышка студентлар чыгышлар әзерлиләр, төрле тәрҗемәләр башкаралар, шулай ук күренекле тәрҗемәчеләр белән очрашулар оештыралар.

Түгәрәк әгъзаларының мактанырлык уңышлары да шактый. Алар, республика күләмендәге «Ел студенты – 2011» бәйгесендә катнашып, «Студентларның фәнни оешмасы» номинациясендә «Прорыв года» дип аталган махсус бүләккә ия була. «КФУның ел студенты – 2011» бәйгесендә «Иң яхшы җәмәгать оешмасы» номинациясендә лауреат исемен яулый.

Казан мэриясе оештырган «Татар телен үстерү һәм куллану» конкурсы, КФУда социогуманитар юнәлеш буенча иң яхшы фәнни эш конкурсында алган җиңүләре, аерым студентларның Казан шәһәре мэры, Оксфорд-Россия фонды, танылган профессор В.Хаков стипендияләренә ия булулары шулай ук зур игътибарга лаек. Студентлар университет, Татарстан, Россия күләмендә уздырылган фәнни-гамәли конференцияләрдә дә актив катнаша, фәнни җыентыкларда мәкаләләр бастыра.

Түгәрәк әгъзаларының тагын бер игътибарга лаек эшләре бар: алар Лаеш районы балалар йортында тәрбияләнүче Надежда Мельникова исемле кызга ярдәм итәләр. Яшь шагыйрәнең шигырьләрен татар теленә тәрҗемә итеп, «Серебряный ручей» җыентыгын бастырып чыгаруда катнашалар. Кызчыкның шатлыклы елмаюы студентлар өчен мактау кәгазьләре һәм рәхмәт хатларыннан да зуррак бәхет.



● Заман таләбе

# «Тискәре караш? Ю-ю-юк!..»

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

16 гыйнвар көнне Филология һәм сәнгать институтында Казан шәһәре Башкарма комитетында эшләүчеләргә сертификатлар тапшыру тантанасы булып үтте.



Ленар Мөхәммәтшин фотосы

Алар ике айдан артык татар һәм инглиз телләрен тирәнтен өйрәнү курсларына йөрде. Бу курслар татар телен өйрәнергә һәм инглиз телен камилрәк белергә теләүчеләр өчен оештырылган. Әйе, әйе, дөрес ишеттегез: бүген татар телен белү шундый дәрәҗәле урыннарда эшләүчеләргә бигрәк тә кирәк. Шул турыда һәм курсларда белем алу тәртипләре белән тулырак танышу өчен, без әлеге курсларны алып баручы филология фәннәре кандидаты, доцент **Ләйсән Хәбир кызы ШӘЯХМӘТОВАга** мөрәҗәгать иттек.

***– Ләйсән Хәбировна, бу курслар кайчаннан бирле эшләп килә? Сез үзегез бу эштә күптән катнашасызмы?***

– Рус телле тыңлаучыларга татар телен өйрәтү курслары инде 90 нчы еллар башыннан – татар теле дәүләт теле статусын алганнан бирле эшли. Әлеге курслар башлыча дәүләт хезмәткәрләре өчен оештырыла. Үзем бу өлкәдә 2002 елдан эшлим.

***– Рус телле кешеләргә татар телен өйрәткәндә, нинди үзенчәлекле алымнар кулланасыз, гомумән, методикагыз нинди?***

– Татар телен чит тел буларак укытуга мин инглиз телен өйрәтү аша килдем (2002 елдан бирле башлап өйрәнүче студентларга инглиз телен өйрәтәм). Татарстанда яшәсәләр дә, рус телле кешеләр өчен татар теле – чит тел. Алар аны, мәсәлән, шул ук инглиз теле кебек, «бераз» белә, ишетеп таный, ләкин авыз тутырып сөйләшә алмый. Чөнки татар теленең структурасы бик авыр, өйрәнүчеләр өчен ул – бетмәс-төкәнмәс кушымчалар дәрьясы (чагыштыру өчен: инглиз теле күпкә җиңелрәк). Шуңа күрә укытуны ике өлешкә – әзерлек курсына һәм төп курска бүлеп укытам. Әзерлек курсында гади аралашу өчен кирәк булган кушымчаларны өйрәнәбез һәм беренче этапта күбрәк тәрҗемәсе кирәк булмаган универсаль сүзләр белән эшлибез (аларда кушымча аерымачык күренә) һәм кушымчаларны да дәрескә берикене генә өйрәнәбез. Ә төп курста материал темаларга бүленеп өйрәнелә. Минем өчен иң мөһиме – укучыларның кызыксынуларын сүндермәү, шуңа күрә дәресләрдә берничә ел дәвамында сыналып, үзләренең эффектлылыгын раслаган күнегүләрне һәм эш төрләрен генә кулланам. (Кызыксынучылар өчен тулырак мәгълүматны Л.Х.Шәяхмәтованың «Татарский с нуля», «Татарский язык: интенсивный курс» дәреслекләреннән таба аласыз).

***– Сез студентлар белән дә эшлисез. Кайсы яшьтә телне тизрәк үзләштерәләр: студентлармы әллә эшли башлаган белгечләрме?***

– Теләсә нинди фәнне үзләштерү тизлеге акыл йөгереклегенә һәм эчке мотивациягә бәйле. Әлбәттә, яшьләргә материал җиңелрәк бирелә, ләкин урта һәм өлкән яшьтәге тыңлаучылар арасында да феноменаль хәтер һәм акыл ияләре очрый.

***– Бу курслар кайда уза?***

– Элек курслар дәүләт учреждениеләре (министрлыклар, район администрацияләре) биналарында узса, бүген алар безнең университет базасында үткәрелә.

***– Эш группалап башкарыламы, әллә аерым-аерыммы, төркемдә ничәләп кеше белем ала?***

– Укыту процессы якынча 15 кешелек группаларда башкарыла. Башлангыч этапта группаларда укыту уңышлырак, чөнки тыңлаучылар бер-берсе белән диалоглар төзеп аралаша, берберсенең үсешен күрә һәм берберсен үсендерә.

***– Курсларның әһәмиятен нидә күрәсез? Сезнең уйлавыгызча, алар кирәкме?***

– Кирәк, әлбәттә. 10 ел укыту дәверендә, төрле яшьтәге тыңлаучылар арасыннан татар телен өйрәтүгә карата бер генә тискәре караш та очратканым юк. Үзем дә, хезмәтемнең кирәклегеен тоймасам, эшли алмыйм мин. Кызыксынып һәм теләп өйрәнәләр, тик 2-3 ай дәвамында бик күпкә өйрәтеп булмый: шунысы кызганыч. Бу арада алар элементар базаны гына үзләштереп өлгерә. Әлеге курслар дәвамлы булса, ягъни укыту процессы, чит телләрне өйрәткән кебек, берничә баскычлы булса, нәтиҗәләр шәбрәк булачак.

***– Төгәл җавапларыгыз өчен рәхмәт Сезгә! Мавыктыргыч эшегездә уңышлар телибез!***

● Кечкенә галимнәр

Хөрмәтле укучылар! Сезне «Кечкенә галимнәр» дип аталган яңа сәхифәдә университетыбызда белем бирүче хөрмәтле галимнәребезнең бәләкәй чагы белән таныштыра башлыйбыз. Бүген Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлеге доценты, шагыйрә, язучы Рифә ХАРРАСОВАның (Рифә Рахман) бала чагыннан бер өземтә тәкъдим итәбез.

# Көянтә

*Балачакның һәр көне – зур бер вакыйга. Ул минем бөтен прозамны орлыкландырып тора. Укучыма тәкъдим иткән хикәядәге Сусылу образының прототибы мин булган кебек, вакыйга-күренешләре дә үз тормышымнан алынган һәм сюжетка ниндидер үзгәрешләр белән генә салынган.*

Сусылу, җилкәсенең әле бу, әле икенче төшенә инә кебек кадалган, сөягенә кадәр авырттырган бармакларны өнәмәгәндәй, читкәрәк тайпылды. Ризасызлыгы йөзенә чыктымы, шунда ук докторның ачулы сүзләре, биек түшәмле бүлмәнең бөтен ярыкларына тулардай көч белән, һаваны яңгыратты:

– Урыныгызда гына торыгызчы! Чат бала-чага инде иллегә җиткән хатынкызы да, әллә нинди авыруларга түзә, табиб каравына да чыдамый!

Регина Владимировна шактый кырыс ханым иде. Ачуын чыгарасы килмичә, Сусылу, кабат өянәге кузгалган билен тоткандай итенеп, элекке урынына басты, турайганрак бер кыяфәт алды.

– Кайдан килеп университет доценты булсын, җилкәсендә гомер буе бүрәнә ташыган авыл агае диярсең! Бөтен нерваларыгыз җилкә турысына җыелган, мускулларыгызны да шул тирәгә оештырып, гәүдәгезне тәмам корыштырган. «Бутадион» кебек мазь сөртеп караганыгыз юкмы? Борчылу аркасында җыерылган тәнне яза ул.

– Сөрткән юк. Соң, карармын.

– Муен чокырына ит үскән кайберәүләргә файдасы тия икән. Мин үзбашка дәвалану яклы түгел дә түгелен. Сезнекендә инде мазь белән генә котыла алмассың. Комплексны дәвалау кирәк. Менә монысы рецепт булыр. Ничек эчәсен авыру картагызга язармын. Массажчыга юллама да әзерлим дә...

Сусылу докторның саргайган кәгазь битендә таракан йөгерешкән кебек эз калдырган каләменә текәлеп онытылып киткән икән.

– Киенә торыгыз. Үзегез кай якныкы соң?

– Авылдан мин. Кукмарадан.

– Алайса аңлашылды. Эт урынына эшли торган як ул. Үз кадерен үзләре белмәүчеләр яши димме? Утызга җиткәндә, умырткасы тулы бүсер булса – шул як хатынкызында булыр. Суны да торбалар китерә торган бер заманда. Хәер, Сезгә көянтә эләккәндер шул әле. Гәүдәгез җитәрлек көянтәләнгә-ә-н.

Шулай. Әнисе, мунча яккан көннәрдә аның казаннарына гына да 17 чиләк су кирәк, ди торган иде. Әле бит эчәргә, савыт-саба юарга. Барысын да ерак чишмәдән ташыдылар алар. Авыл уртасындарак иң тәмле сулы чишмә булгангамы, бөтен кеше нәкъ менә шуныкын эчәргә тырыша иде. Югыйсә бакча



Рифә Харрасованың 1 яшь тә 10 айлык чагы

башларыннан ерак түгел торналы кое да, кисмәкле чишмә дә бар, болын коесы дип аталган чишмәгә дә ерак түгел, ә барыбер суны ерактагысыннан, текә тау астыннан агып чыга торганыннан эчәләр, керне дә исе саф була дип, нәкъ менә аның янындагы яссы улакларда чайкыйлар. Кайвакыт чират көтеп, тәүлек үтә, суының салкынлыгыннан кышларын кулларың күшегә, аяк табаннарың чишмә ярындагы бозларга кубармаслык булып ката.

Бервакыт әнисенең, айһай озак тордың, үзем барып килердәй булдым, дигәненә, миннән алда егерме сигез көянтә иде, дип әйткәнен хәтерли, иртән китеп кичкә авышканда кайткан иде шул. Хәер, кышкы киче дә аның икедә-өчтә башлана, ә улакта су тамчылап кына, ташлар арасыннан кысылып чыгып кына, бик нык чистарынып кына ага. Ә бит бар иде мул сулы чишмәләр дә, бар иде. Аның монысы да ул сабыйрак чакларда, агач улакларны тимер торбаларга алмаштырганчы, ыргылып-ыргылып аккандай хәтердә калган.

Бервакыт язгы сулар кер агарта дигәч, болын буендагыларга кызыгып, паласкапчыкларны Бөрдә генә чайкаганнар иде, әнисе, төсен бер дә ошатмады, барыбер яңадан юып, Ерак чишмәдә чайкадылар. Ерак чишмә дигәннән, аның исеме дә һәр урам телендә төрлечә йөри иде. Сусылулар турында чишмәләр бик күп булгач, аларның күршетирәсе арасында ул Ерак чишмә, Тау башы чишмәсе кебегрәк исемнәр белән аталды.

Регина ханым язу-сызуны тиз тотар сыман. Коридорда чират көтүчеләр чишмә буе чиратындагылар саныннан ким түгел. Чишмә буе дигәннән, һәр яңалыкны Сусылу нәкъ менә шунда ишетте, егетләр белән дә еш кына чишмә юлында танышты. Инеш ярыннан чишмәгә илтүче, тау-ташлар аша узучы сукмаклар бик тар иде шул. Каршы килүче егетләр кочагына алып керерлек тар... Сусылу гына сер бирә, буйсына торганнардан түгел. Очратыйм дип, чишмә буена төшеп көтеп утыручыны күрсә, я тыкрыктан кире күтәрелә дә урам аша бара, чишмәгә күпердән чыга, я сукмакны чибәр егеткә калдырып, галошларына су кертеп, инеш буйлап кына китеп бара.

Инеш суы үзе дә бик чиста. Төбе тулы чуерташ, мунча ташы, мич ташы... Тирә-ягын карап тотучылар җитәрлек. Сәвабы бик күп икән, ир кеше пенсиягә чыктымы, кышын юлларын көри, язын чүптән арындыра, җәен артык куакларын кисә. Хәзер генә ул чишмәсе үзе дә, чүп-чар урынына, инеш буе сазлыкка, баткаклыкка әверелгән.

– Киенеп беттегезме? Ярый. Яхшы. Хәзер бар да хәзер була.

Киенергә диюе генә ансат. Фатирында булса, күкрәген белендерми торган җылы калын кофтасын гына киеп алыр иде дә. Болай... Бюстгальтерымны эләктерегезче, дип, табибка эндәшмәс бит инде. Аркасына ни каерып кулы җитмәгәч, каптырмаларын алгы якта эләктерим дип уйлаган иде, инде кирегә бора алмый азаплана. Җәфаланды, җәфаланды да, Регина ханымның язу белән мәшгульлеген күреп, тиз генә вак-төяк киемнәрен шытыры ачык редикюленә тондырды – күлмәген шәрә тәненә генә киде.

– Көянтә дигәннән... Онытым бию түгәрәгенә йөри. Үзләренә яраклы көянтә табарга кушканнар. «Каз өмәсе» дигән бию бииселәр, имеш.

– Ие шул. Бар андый бию. Җитәрлек биедек без аны яшь чакта, – дип шаяртҡандай итте Сусылу, тик табиб кына аңламады.

– Көзге өмәләрдә унар кыз, көянтәгә казлар асып, чишмә буена төшәр идек. Кемнеке аграк, кемнеке симезрәк, дип карап каласыларын белгәндә, билләр дә турая, җилкәләр дә языла, адымнар да ешая, ваграк була.

– Сөйләп торган буласыз, – дип кырт кисте табибә. – Аның каравы менә хәзер язылмый! Ярар, барыгыз, тиздән массажист кайтып китә. Минем әманәтне онытмагыз, дәвалау – миннән, көянтә – Сездән.

***(Дәвамы киләсе санда).***

Илһам канатында



Алина Васильева 1991 елның 26 октябрендә Мамадыш районы Дусмәт авылында дөньга килә. 15 яшеннән хикәяләр, мәкаләләр, шигырьләр яза. Әдәби ижаттан тыш, жырларга, биергә ярата. Мамадыш районы керәшен яшьләренен оешыру комитеты әгъзасы булып тора. Хәзерге вакытта КФУ Алабуга филиалының психология һәм педагогика факультетында III курста белем ала.

# Бәхет

*Нияз йокыдан торуга ук тәрәзә янына йөгерен килде. Кара, тышта ничек матур! Беренче кар ява! Кубәләктәй бөтерелеп, кар бөртекләре жиргә килеп куналар.*

*– Ура! Кыш житкән! – дип кычкырып жибәрде малай, үзе дә сизмәстән. Каршы каравата дусты Саматның йоклап ятканын бөтенләй онытkан иде ул.*

*– Ай-яй, дустымны уята язганмын икән! Беренче кар яуганын да күрмичә кала инде, – дип әйтеп куйды Нияз, уфтанып. – Әйдә, йокласын, әнә ничек итеп елмая. Берәр төш күрә, ахрысы. Аның янына әти-әнисе килгәндер, күрәсең, – дип уйлап куйды малай.*

*Нияз белән Самат балалар йортында тәрбияләнәләр. Икесенең дә әтисе дә, әнисе дә юк. Кечкенәдән үк ташлап киткәннәр аларны. Шуңа күрә балалар әти-әни жылысына мохтаж. Әти-әниләрен күрү телэге,кайчан да булса алар белән очрашу өмете кечкенә йөрәкләргә мәңгелеккә кереп оялаган.*

*...Нияз,урамдагы могжизага сокланып, хыяллар диңгезенә чумды. Әнә ул, бәләкәй генә самолетка утырып, күктә оча. Кар бөртекләре монда да бар икән. Алар,Ниязны күргәч, бөтенләй үк бии башладылар. Самолетның тәрәзәсенә сарылалар. Әйтерсең, шулай итеп алар малайга сәлам бирәләр.*

*Ниязның уйларын кинәт кенә ачылган ишек тавышы бүлде.*

*– Нияз, балакаем, сине чакыралар, – дип, үзенә дәште аны балалар йорты директоры Сабира апа.*

*Малай сискәнеп китте. «Кем икән?» – дигән сорау аптыратты. Нияз шатланырга да, елмаерга да белмәде.*

*Коридорга чыкты. Анда бер апа белән бер абый басып тора иде.*

*– Менә Нияз шушы малай була инде... – Сабира апа үзенең артына ящеренгән кечкенә егетне алга ыгарды.*

*– Исәнме, Нияз! Без синең яңа әти-әниең, – дип, апа малайны кочагына алды.*

*Ниязның күзләренә яшь тулды. Ул нишләргә дә белмәде. Аңа моңа кадәр таныш булмаган апаны кысып кочаклады.*

*– Әти-әни! – дип, кечкенә куллары белән абыйга сузылды. Ниязның битеннән бәхет яшьләре тәгәрәде.*

*Кинәт Нияз Саматны исенә төшерде. «Ә ул нәрсә эшләр? Минсез ул нечек яшәр?» – дигән уйлар нәни күңелен биләп алды.*

*– Әти-әни, мин үземнең иң кадерле кешеләремне таптым, ә менә минем дустымның беркеме дә юк. Әйдәгез, аны да үзебез белән алып китик! Саматның миннән башка бер кешесе дә юк бит. Зинһар өчен, – диде Нияз,бүлмәсенә таба карап.*

*– Ярый соң, улым, алырбыз. Кайгырма, – диделәр апа белән абый һәм малайны тагын да катырак кысып кочакладылар.*

Алар бездә укыган

Рамил ХАННАНОВ

# Бүләк

Фронтовик-язучы, 1950-1954 елларда безнен уку йорты студенты Хисам Камалга шушы көннәрдә 85 яшь тулды.



Урын өстендә ятучы әдипне Татарстан Республикасы мәдәният министры Айрат Сибагатуллин һәм Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов котлады. Алар кулыннан Хисам Камал Твардовскийның тууына 100 ел тулуга багышланган медаль алды. Таныклыкка Россия мәдәният министры Александр Авдеев кул куйган.

### Әдип турында

Хисам Камал 1926 елның 14 апрелендә Татарстанның Әлмәт районы Кама-Исмәгыйль авылында игенче гаиләсендә туа. 1940 елда жидееллык мәктәпне тәмамлагач, туган авылының күмәк хужалыгында эшли. 1943 елның ноябрендә унсигез яше дә тулмаган үсмер егетне гаскәри хезмәткә алып, 1944 елның апреленә кадәр мәгълүм Суслонгер-Сурок хәрби лагерьларында хәзерлек курслары үткәннән соң, май башында туп-туры фронтка озаталар. Ул Икенче Балтыйк буе фронты гаскәрләре составында бик күп канлы бәрелешләрдә катнаша, 1944 елның жәендә яраланып, өч ай чамасы госпитальдә ятып чыга, аннары янадан фронтның алгы сызыгына жибәрелә, артиллерия полкының кыр элемтәчесе сыйфатында Латвия жирләре аша Польша чикләренә кадәр сугышчан юл уза. 1945 елның 26 февралендә Х.Камалов кабат яралана һәм яндан госпитальгә озатыла. Бу юлы жәрәхәт бик житди булып, егеткә ел ярым төрле госпитальләрдә дәваланырга туры килә, ахырда бер аягын тәптән кистереп, 1946 елны ул инвалид булып өенә кайта.

Шул ук елны Х.Камалов Татарстанның Бөгелмә шәһәрендәге педагогия училищесында укый башлый, училищены тәмамлагач, 1950-1954 елларда Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укуын дәвам итә. Аннан 12 ел дәвамында Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә мөхәррир булып эшли. 1967 елдан башлап ул – язучы-профессионал.

1955-2000 еллар арасында әдипнең татарча һәм рус теленә тәржемәдә барлыгы егерме сигез китабы дөнья күрә. «Һәркемнең гомере бер генә» һәм «Безне өйдә көтәләр» романнары өчен Х.Камал 1986 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. 2001 елда исә, татар әдәбиятын үстерүдә ирешкән зур казанышларын искә алып, ана Татарстан Республикасының Халык язучысы дигән шәрәфле исем бирелде. Хисам Камал – 1958 елдан СССР һәм Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы.

### «Язмышым – әсәрләремдә...»

«Баксан, мин инде шактый гомер кичергән бер әдип икәнмен. Уен эшмени, «язучы булам», дигән кебегрәк уй белән кулыма каләм алганга да ярты гасырдан артыграк вакыт узып киткән икән. Әдәби жәмәгатьчелек минем ижатымны бик тиз күреп алды. Ижатымның башлангыч чорында миңа Гомәр Бәширов, Шәйхи Маннур, Әнвәр Давыдов һәм, әлбәттә, Сибгат Хәким кебек могтәбәр затлар зур ярдәм күрсәттеләр; алар миңа, ул еллардагыча әйтсәк, «солдат поэзиясе»нең бер вәкиле буларак, һәрдаим олы ышаныч белдерделәр. Чынлап та, мин үз ижатымда тормышчынбарлыкны матур бизәкләргә төрмичә генә, бөтен кырысылыгында тасвирларга тырыштым.

Әйе, мин бит фронтовик-солдат та идем, сугыш дигән мәхшәрнең авыр йөген, ачы хәсрәтен үз жилкәмдә татыгра туры килде. Укучыларыма да шул хакта сөйләп бирәсем, гыйбрәт итеп тасвирлап күрсәтәсем килә иде. Кем әйтмешли, шигырь кысалары тар кебек тоелды. Шул рәвешле, үзем дә сизмәстән, прозаик булып киттем. Ә моның өчен бар көченне биреп, жәелеп эшләргә кирәк.

Аннары мин үз укучымны таптым дип әйтә алам, язучы өчен моннан да татлырак кичерешнең булуы мөмкин түгел. Шөкер, житәкче даирәдә дә хезмәтемне күреп ала белделәр. Мин бар булган сәләтемне биреп, ихлас күңелемнән халкым өчен – татар укучысы өчен яздым һәм халкым язучысы була алуым белән чиксез бәхетлемен.

Шушы унайдан минем тагын бер генә сүз әйтеп узасым килә. Мин көндәлек тормышта алдашуны яратмыйм һәм ижатымда да алдашмаска тырыштым. Бу минем яшәеш һәм иҗади кредом булды. Кырыс хакыйкать – ялган-матур бизәкләргә караганда, бик күпкә саваплырак гамәл, минемчә».

*matbugat.ru сайты мәгълүматлары файдаланылды*

Шамил Абдюшев фотосы

Сәламәтлек

# Һәрдаим нығыту кирәк!

Зилә ФӘСХИЕВА, хәбәрче

Кышын сәламәтлек турында кайгырту аеруча да мөһим. Ләкин күпләребез кышны кыска һәм салкын көннәрдә өйдән чыкмыйча гына жылы юрган астында ятуны кулай күрә.

Бу иң ялгыш фикерләрнең берсе, чөнки аз хәрәкәтләнү, гел бер бүлмәдә генә булу организмның иммун системасын какшата. Берничә гади киңәшне истә тотсагыз, сәламәтлеккә берниндидә куркыныч янамас!

Иң беренче чиратта, дерес туклану турында онытмаска кирәк. Витаминнарга бай продуктларга өстенлек бирү организмга бик файдалы йогынты ясаячак. Шулай ук күп итеп су эчәргә кирәк. Кыш көне тән тиресе кибә, корый. Бу аңа тиешле дәрәҗәдә дым житмәү белән бәйле. Ким дигәндә, көнгә 8 стакан су эчкән кеше үзен яхшы хис итә.

Тән тиресен карарга да онытмаска кирәк. Урамга чыкканда, биткә махсус крем сөртеп йөрүне яхшы гадәткә кертегез. Болай эшләмәгән очракта, бит тиресе кибәчәк, аны яңадан элеккеге хәләнә кайтару өчен дә байтак вакыт кирәк булачак.

Физик күнегүләр эшләү инде һәрдаим «модада». Ә менә кыш көне ул сәламәтлек өчен аеруча файдалы. Урамда чаңгы, чана, тимераякта шуу да кәефне генә түгел, организмның вирусларга каршы көрәшүчәнлеген арттырып жибәрәчәк.

Вакытыгызның күпчелек өлешен саф һавада үткәрергә тырышыгыз! Саф һава үпкәләрне тиешле күләмдә кислород белән баета, энергия чыганагы булып тора. Хәтта әз генә урамда йөреп керү дә кешенең организмының эшләү процессын активлаштыра икән. Ә бу исә сәламәтлекне ныгытуның бер юлы булып тора!



Шулай ук өй эчендәге һаваны да ешрак жилләтеп торырга онытмагыз. Чөнки кыш көне жылылыкны саклап калу максатыннан, бүлмәдәге һаваны алыштырырга онытып жибәрәбез. Бу очракта бүлмәдәге дымлылык кими һәм шул сәбәпле сулыш органнары белән бәйле күп кенә авырулар килеп чыгарга мөмкин. Мәсәлән, астма авыруы.

Кулларны юып йөрү сәламәтлек өчен кирәкле факторларның иң әһәмиятлесеедер, миңа калса. Чөнки без кайда гына бармыйбыз, нәрсәләр белән генә эш итмибез! Инфекция артуын телэмәсәгез, куллар гигиенасын саклагыз.

Салкын кышкы көннәрдә үзенә генә бикләнеп өйдә утырырга һич кенә дә ярамый! Дуслар белән күрешергә, аралашырга кирәк! Үзегезне физик яктан күпме активрак тотсагыз, организмыгыз да шуның кадәр сәламәтрәк булачак!

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Ижат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева, Э.Р.Ибраһимова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты

Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 292-22-91, 89053711571.
Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.

Газета бушлай таратыла